**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы «Ульяновка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге гражданнары җыены карары**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлеге составына керүче Ульяновка, Девичья Поляна һәм
Сосновка авылы торак пунктларында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**18.10.2021 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 18 октябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2022 елда Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм дәими яшәүче һәр балигъ булган кешегә 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Девичья Поляна, Нагорный, Саминовка, Сосновка һәм Ульяновка торак пунктларында урам утларын монтажлауга, урнаштыруга, ремонтлауга, карап тотуга һәм хезмәт күрсәтүгә, урам утларын куллану чыгымнарын түләүгә, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга;
- Девичья Поляна, Нагорный, Саминовка, Сосоновка һәм Ульяновка торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнарына;
- Проект- смета документациясен әзерләүгә, топографияне, авыл территорияләрен төзекләндерү буенча экспертиза үткәрүгә чыгымнар (Ульяновка авылы тротуарына);
- Бульдозер көрәге сатып алуга;
- Ульяновка авыл җирлегендә урам-юл челтәрен төзекләндерү югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу: вак таш сатып алу, фракция 20-30 мм.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 564 (биш йөз алтмыш дүрт) катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 290 (ике йөз туксан) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 290 катнашучы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге составына керүче Ульяновка, Девичья Поляна һәм Сосновка торак пунктларында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2022 елда Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм дәими яшәүче һәр балигъ булган кешегә 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш, һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Девичья Поляна, Нагорный, Саминовка, Сосновка һәм Ульяновка торак пунктларында урам утларын монтажлауга, урнаштыруга, ремонтлауга, карап тотуга һәм хезмәт күрсәтүгә, урам утларын куллану чыгымнарын түләүгә, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга;

- Девичья Поляна, Нагорный, Саминовка, Сосоновка һәм Ульяновка торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнарына;

- Проект- смета документациясен әзерләүгә, топографияне, авыл территорияләрен төзекләндерү буенча экспертиза үткәрүгә чыгымнар (Ульяновка авылы тротуарына);

- Бульдозер көрәге сатып алуга;

- Ульяновка авыл җирлегендә урам-юл челтәрен төзекләндерү югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу: вак таш сатып алу, фракция 20-30 мм.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Ульяновка авылы, Центральная урамы, 44 нче йорт, Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми интернет сайтында бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары Федулова. И.В.